Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XLVII-1**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 2 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 – 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында”гы карары хакында

2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 маддәсе 2 өлешенең 2 пункты, 35 маддәсе 10 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 22 маддәсе 8 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 17 маддәсе 3 өлешенең 2 пункты, 30 маддәсе 1 өлешенең 3 пункты, 80,81 маддәләре, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәнең 9 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында”гы карары проектын хупларга һәм ачык тыңлауларга чыгарырга (кушымта №1);

2.Расларга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында”гы карары проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен (кушымта №2);

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында”гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибен (кушымта №3).

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында”гы карары проекты буенча ачык тыңлауларны Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт,

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының утырышлар залы адресы буенча 2019 елның 20 декабренә 17 сәгатькә билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында”гы карары проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм гомумиләштерү буенча оештыру комитетын түбәндәге составта төзергә:

Әхмәтҗанова Фирдания Гомәр кызы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы урынбасары, оештыру комитеты рәисе;

Гаянов Мөдәррис Нургали улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясе рәисе, оештыру комитеты рәисе урынбасары;

Әхмәтвәлиева Резеда Габделәхәт кызы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы Аппаратының оештыру бүлеге башлыгы, оештыру комитеты сәркатибе;

Ногманова Илсия Малик кызы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе, оештыру комитеты әгъзасы;

Хәкимуллин Айрат Альберт улы – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлеге башлыгы, оештыру комитеты әгъзасы.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә ачык тыңлауларда әйтелгән һәм аны тикшерү барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында”гы карары проектын эшләп бетерергә һәм карар проектын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына икенче укылышта карауга кертергә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

6. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы<br>
Балык Бистәсе муниципаль район<br>
Башлыгы И.Р. Тажетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2019 елның 2 декабрендәге XLVII-1 номерлы карарына кушымта №1

**Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советының
“2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына
Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
бюджеты турында” карар проекты**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 15, 184.1 маддәләре, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль законның 35 маддәсе 10 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасының 2004 елның 28 июлендәге “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 45-ТРЗ номерлы Законының 22 маддәсе 8 өлешенең 2 пункты, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 30 маддәсе 1 өлешенең 3 пункты, 80,81 маддәләре нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

**1 маддә**

1.2020 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 709971,80 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты чыгымнарының фаразлана торган гомуми күләмен 709971,80 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты кытлыгының чик күләмен 0,0 мең сум итеп.

2. 2021 елга һәм 2022 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетының төп сыйфатламаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2021 елга 718399,92 мең сум һәм 2022 елга 726305,64 сум итеп;

2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты чыгымнарының фаразлана торган гомуми күләмен 2021 елга 718399,92 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 5402,50 мең сум итеп һәм 2022 елга 726305,64 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 9848,80 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район бюджеты кытлыгының чик күләмен 2021 елга 0,0 мең сум, 2022 елга 0,0 мең сум итеп.

3. 2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

**2 маддә**

1.2021 елның 1 гыйнварына :

1) Балык Бистәсе муниципаль районы эчке бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум, шул исәптән Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында муниципаль эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Балык Бистәсе муниципаль районы тышкы бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум, шул исәптән Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча чит ил валютасында муниципаль тышкы бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга.

2. 2022 елның 1 гыйнварына:

1) Балык Бистәсе муниципаль районы эчке бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум, шул исәптән Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында муниципаль эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Балык Бистәсе муниципаль районы тышкы бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум, шул исәптән Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча чит ил валютасында муниципаль тышкы бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга.

3. 2023 елның 1 гыйнварына:

1) Балык Бистәсе муниципаль районы эчке бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум, шул исәптән Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча Россия Федерациясе валютасында муниципаль эчке бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга;

2) Балык Бистәсе муниципаль районы тышкы бурычының иң югары чиген 0,00 мең сум, шул исәптән Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль гарантияләре буенча чит ил валютасында муниципаль тышкы бурычының иң югары чиген нуль күрсәткече белән расларга.

4. Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән ихтимал гарантия очраклары буенча Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетының Балык Бистәсе муниципаль районы гарантияләрен үтәүгә каралган бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 2020 елга, 2021 елга һәм 2022 елга 0,00 мең сум күләмендә расларга.

**3 маддә**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына керемнәрнең фаразлана торган күләмнәрен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 маддә**

2020 елда һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетына муниципаль район муниципаль унитар предприятиеләре табышының 2019, 2020 һәм 2021 еллар йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган

өлеше  2019, 2020 һәм 2021 елларның 1 июленә кадәр тиңдәшле рәвештә чиста табышның 30 проценты күләмендә күчерелә дип билгеләргә.

**5 маддә**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы  бюджеты керемнәренең баш администраторлары  исемлеген  3 нче кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы  бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары  исемлеген  шушы карарга бирелгән   4 нче кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

**6 маддә**

1.2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетының  бюджет  ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре,  максатчан маддәләре, чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре) буенча  бүлүне әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты чыгымнарының  ведомство структурасын  әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

3. 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чорына  Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетының  бюджет  ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан маддәләре (муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең  программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре (төркемнәре һәм төркемчәләре), бүлекләре, бүлекчәләре  буенча бүлүне әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Муниципаль район бюджеты  бюджет  ассигнованиеләренең гавами (ачык) норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми күләмен 2020 елга 1200,0 мең сум, 2021 елга 1250,00 мең сум, 2022 елга  1680,00 мең сум  күләмендә расларга.

**7 маддә**

1.”Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы” муниципаль берәмлеге бюджетыннан  муниципаль район бюджетына муниципаль  учреждениеләрне тәэмин итү чыгымнарын үтәүгә башка бюджетара трансфертларны  2020 елга 2154,60  мең сум, 2021 елга 1929,40 мең сум һәм 2022 елга 1680,00 мең сум  күләмендә  әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

2.Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына  әлеге маддәдә күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны  җирлекләр бюджетларында карауны  тәкъдим итәргә.

**8 маддә**

Җирлекләрнең бюджет  тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен 2020 елга 59501,40 мең сум, 2021 елга 60875,00 мең сум, 2022 елга 62432,90 мең сум күләмендә әлеге карарга 9 нчы кушымта нигезендә бүлеп  расларга.

**9 маддә**

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпне гамәлгә ашыру буенча дәүләт вәкаләтләрен тормышка ашыруга  җирлекләр бюджетларына субвенцияләр күләмен 2020 елга 2393,90 мең сум, 2021 елга 2397,50

мең сум, 2022 елга 2435,00 мең сум күләмендә әлеге карарга 10 нчы кушымта нигезендә бүлеп расларга.

**10 маддә**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертларны 2020 елга 536626,60 мең сум, 2021 ел план чорына 546992,72 мең сум, 2022 ел план чорына 554365,84 мең сум күләмендә әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә расларга.

**11 маддә**

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2020 елга 17000,00 мең сум, 2021 елга 19000,00 мең сум, 2022 елга 20000,00 мең сум күләмендә расларга һәм аларны муниципаль районның җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы юлларында тиңдәшле рәвештә 2020, 2021, 2022 елларга юл эшләре Программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**12 маддә**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары 2020 елда һәм 2021, 2022 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләрнең, учреждениеләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары работникларының санын, шулай ук аларны тотуга чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

2.Җирлекләрнең җирле үзидарә органнарына 2020 елда һәм 2021, 2022 еллар план чорында муниципаль хезмәткәрләрнең, учреждениеләр һәм бюджет өлкәсенең башка оешмалары работникларының санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

**13 маддә**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешү нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

**14 маддә**

Товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар буенча түләү өчен бирелгән 2020 елның 1 гыйнварына калган акчалары, әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә 2019 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмаган күләмдә 2020 елда, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**15 маддә**

Әлеге карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**16 маддә**

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2019 елның 2 декабрендәге XLVII-1 номерлы карарына кушымта №2

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында” карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен һәм гражданнарның аны тикшерүдә катнашуын исәпкә алу тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында” карар проекты буенча тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына язма формада түбәндәге үрнәк нигезендә төзәтмәләр таблицасы рәвешендә кертелә:

| N п/п | Пункт, подпункт | Текст проекта решения | Текст поправки | Текст проекта решения с учетом поправки | Автор поправки (Ф.И.О, адрес, телефон, место работы (учебы) |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |
| | | | | | |

1.№ п/п 2. Пункт, пунктча 3.Карар проекты тексты 4.Төзәтмә тексты 5.Төзәтмәне исәпкә алып карар проекты тексты 6.Төзәтмәнең авторы (Ф.И.А.и.,адрес, телефон, эш (уку) урыны)

Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча юллана: 422650,Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт, 4 кабинет; почта аркылы: 422650,Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт яисә 2-30-12 факсы буенча.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 8 дән 17 сәгатькә кадәр 2019 елның 19 декабренә хәтле Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында” карар проекты Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан ителгән (урнаштырылган) мизгелдән башлап кабул ителәләр.

2. Чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашуга гариза түбәндәге адрес буенча бирелә: 422650,Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт, 4 кабинет; почта аркылы: 422650,Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48 йорт яисә 2-30-12 факсы буенча.

Гаризалар эш көннәрендә 8 дән 17 сәг.кә чаклы ачык тыңлаулар үткәрелү датасына кадәр 7 көннән соңга калмыйча кабул ителә.

3. Гражданнарның тәкъдимнәре Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты хезмәткәрләре тарафыннан теркәлә һәм карау өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының бюджет, финанслар, икътисад, җирле салымнар һәм эшкуарлык буенча даими комиссиясенә тапшырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2019 елның 2 декабрендәге XLVII-1 номерлы карарына кушымта №3

**Татарстан Республикасы**
**Балык Бистәсе муниципаль район Советының**
**“2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында” карар проекты буенча ачык тыңлаулар уздыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының “2020 елга һәм 2021 һәм 2022 еллар план чорына Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы бюджеты турында” карар проекты буенча ачык тыңлаулар (алга таба – ачык тыңлаулар, тиңдәшле рәвештә карар проекты) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставының 17 маддәсе, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2018 елның 4 сентябрендәге XXXIII-2 номерлы карары белән расланган “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгатьчелек фикер алышулары) оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәнең 9 маддәсе нигезендә үткәрелә.

2. Үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чыгыш ясау хокукы белән ачык тыңлауларда катнашучылар булып язма рәвештә үзләренең гаризаларын ачык тыңлаулар үткәрелү датасына хәтле җиде көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советына биргән районда яшәүчеләр тора.

3. Ачык тыңлауларда чыгыш ясау хокукыннан башка гына катнашучылар булып районда яшәүчеләрнең һәрбер кызыксынучысы торырга мөмкин.

4. Катнашучыларны теркәү ачык тыңлаулар башланганчы 30 минут алдан башлана.

5. Ачык тыңлауларда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы урынбасары – карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу һәм гомумиләштерү буенча оештыру комитеты рәисе рәислек итә.

6. Ачык тыңлаулар рәислек итүченең кереш сүзе белән башлана, ул залда булучыларга тикшерелә торган мәсьәләнең асылы, тыңлауларны үткәрү тәртибе хакында мәгълүмат ирештерә.

7. Беркетмәне рәсмиләштерү, кергән тәкъдимнәрне, киңәшләрне исәпкә алу өчен рәислек итүче тәкъдиме буенча җитәкчесе һәм ике әгъзасы составында ачык тыңлауларның секретариаты сайлана.

8. Төп доклад белән оештыру комитеты рәисе чыгыш ясый.

9. Ачык тыңлауларның чыгыш ясау хокукына ия катнашучылары гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чират тәртибендә үзләренең тәкъдимнәрен дәлилләү өчен чакырылалар.

10.Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан артык дәвам итәргә тиеш түгел.

11. Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаучыларга чыгыш тәмамланганнан соң рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

12. Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар барышына тыгылырга, аларны өзәргә һәм үткәрүгә комачауларга хаклы түгел.

13. Ачык тыңлауларны үткәргәндә тәртипне үтәү ачык тыңлауларда катнашу өчен мәҗбүри шарт булып тора.

14. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан үткәрү тәртибен бозу очрагында рәислек итүче аларны залдан чыгарып җибәрүне таләп итәргә хаклы.

15. Чыгышлар төгәлләнгәннән соң рәислек итүче ачык тыңлаулар барышында әйтелгән тәкъдимнәр, киңәшләрне аныклау өчен ачык тыңлаулар секретариаты җитәкчесенә сүз бирергә мөмкин.

16. Ачык тыңлауларда катнашучыларның барлык замечание һәм тәкъдимнәре ачык тыңлаулар беркетмәсенә теркәлә. Ачык тыңлаулар беркетмәсе билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы материалларында саклана.

17. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) оештыру комитеты тарафыннан әзерләнә.

18. Ачык тыңлаулар йомгаклары буенча нәтиҗә (бәяләмә) халыкка игълан ителергә тиешле.

19.Ачык тыңлауларны үткәрүнең оештыру һәм матди-техник тәэмин ителеше Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы аппараты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов